| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>БОЛЬШЕПОДБЕРЕЗИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ОЛЫ ПОДБЕРЕЗЬЕ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

12 ноябрь, 2024 ел Олы Подберезье авылы № 3

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районының Каргалы авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге Уставының 22статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлегенең Каргалы торак пунктында РТ, Кайбыч районы, Каргалы авылы, Кызыл Герой урамы, 16 адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында 2024 елның 27 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2025 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге Каргала торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаиләләренең балигъ булган әгъзаларыннан тыш даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәл әләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

« РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Олы Подберезье авыл җирлеге башлыгы О.М. Емельянова